ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул.Ш.Маннура, д.72а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

Ш.Маннур ур., 72а нче йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-44; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru

Карар
20 сентябрь 2017 ел

Постановление
№ 20

## Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14,22, 56 статьялары, " Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясының 1 п., «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башкарма комитеты К А Р А Р БИРӘ:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2018 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел пожар куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын булдыру :

Пожар гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру:

- Олыяз торак пунктында, Түбән Козгынчы торак пунктында, Югары Козгынчы торак пунктында.

2. Авыл жирлеге торак пунктларында су белән тәэмин итү:

Олыяз торак пунктында су алу башнясын әйләндереп алу

Тулбай торак пунктында су алу башнясын әйләндереп алу

Югары Козгынчы башнясында су башнясын әйләндереп алу

Су скважинасы эйләндереп алу: Олыяз, Түбән Козгынчы, Кыраул, Югары Козгынчы, Дусай, Тулбай торак пунктларында

3.Җирлекнең торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
Түбән Козгынчы торак пунктында Октябрь урамында юлны вакташ җәеп ремонтлау.
Дусай һәм Тулбай торак пунктларында мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләре территориясе янында автомобиль юлларында яңа юл билгеләре һәм ясалма тигезсезлекләр сатып алу һәм урнаштыру.

« ӘЙЕ »  « ЮК »

2. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгы И.Я.Хаевка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе  И.Я.Хаев